**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2017 ел, 27 март | № 186

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә таләпләрне раслау хакында» 2016 ел, 20 апрель, 242 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә таләпләргә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә таләпләрне раслау хакында» 2016 ел, 20 апрель, 242 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә таләпләргә, аларны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры | И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 24 апрель, 242 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 27 март, 186 нчы карары редакциясендә)

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИХТЫЯҖЛАРЫН ТӘЭМИН ИТҮ ӨЧЕН САТЫП АЛУЛАР ӨЛКӘСЕНДӘ НОРМАЛАШТЫРУ ТУРЫНДА ХОКУКЫЙ АКТЛАР ЭШЛӘҮ ҺӘМ КАБУЛ ИТҮ ТӘРТИБЕНӘ, ӘЛЕГЕ АКТЛАРНЫ КАРАП ТОТУГА ҺӘМ АЛАРНЫҢ ҮТӘЛЕШЕН ТӘЭМИН ИТҮГӘ ТАЛӘПЛӘР

1. Әлеге документ түбәндәге хокукый актларның эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә таләпләрне (алга таба – Таләпләр) билгели:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый торган:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт бюджеттан тыш фондлары белән идарә итү органнары (тиешле территориаль органнарны һәм ведомстводагы казна учреждениеләрен дә кертеп) функцияләрен тормышка ашыруга норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләрен;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы дәүләт бюджеттан тыш фондлары белән идарә итү органнары һәм аларның территориаль органнары, алар ведомствосындагы казна учреждениеләре, бюджет учреждениеләре һәм дәүләт унитар предприятиеләре оешмалар тарафыннан сатып алына торган товарларның, эшләрнең, хезмәтләрнең аерым төрләренә (шул исәптән товарлар, эшләр, хезмәтләрнең чик бәяләренә) карата таләпләрне билгеләү кагыйдәләрен;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт бюджеттан тыш фондлары белән идарә итү органнары һәм алар ведомствосындагы казна учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы дәүләт бюджеттан тыш фондлары белән идарә итү органнары, аларның территориаль органнары (бүлекчәләре) һәм алар ведомствосындагы казна учреждениеләре, бюджет учреждениеләре һәм дәүләт унитар предприятиеләре сатып ала торган аерым төр товарлар, эшләр, хезмәтләргә (шул исәптән товарлар, эшләр, хезмәтләрнең чик бәяләренә) таләпләрне.

2. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет

учреждениесенә (алга таба –ТР ИСТҮ) Таләпләрнең 1 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карарлары проектларын (алга таба – карарлар проектлары) эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

3. Хокукый актлар проектларын җәмәгатьчелек тикшерүе максатларында фикер алышу үткәрү өчен хокукый актлары проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына керткәнгә кадәр ТР ИСТҮ хокукый актлар проектларын һәм аларга аңлатмаларны Таләпләрнең 4 пунктында билгеләнгән вакытка сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасына урнаштыра.

4. Җәмәгатьчелек тикшерүе максатларында фикер алышулар үткәрү вакыты Таләпләрнең 1 пунктында күрсәтелгән хокукый актлар проектларын сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасына урнаштырган көннән соң җиде календарь көненнән кимрәк була алмый.

5. ТР ИСТҮ җәмәгать берләшмәләре, юридик һәм физик затларның әлеге Таләпләрнең 4 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнгән вакытта электрон яки язма рәвештә кергән тәкъдимнәрен гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында Россия Федерациясе законнары нигезендә карап тикшерә.

6. ТР ИСТҮ җәмәгать берләшмәләре, юридик һәм физик затларның тәкъдимнәрен һәм (яки) искәрмәләрен карап тикшергән көннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча бу тәкъдимнәрне һәм (яки) искәрмәләрне һәм аларга җавапларны сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасына урнаштыра.

7. Әгәр җәмәгатьчелек тикшерүе максатларында фикер алышу процессында җәмәгать берләшмәләре, юридик һәм физик затлардан Таләпләрнең 1 пунктында күрсәтелгән һәм сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасына урнаштырылган хокукый актлар проектларына тәкъдимнәр һәм (яки) искәрмәләр керсә һәм алар мондый проектларны урнаштырган орган тарафыннан нигезле дип танылса, ТР ИСТҮ әлеге хокукый актлар проектларына үзгәрешләр кертә.

8. Әлеге Таләпләрнең 1 пунктының бишенче һәм алтынчы абзацларында күрсәтелгән хокукый актлар алар кабул ителгән көннән соң җиде эш көне эчендә сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасына урнаштырыла һәм әлеге Таләпләрдә каралган тәртиптә елына кимендә бер тапкыр актуальләштерелергә тиеш.

9. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт бюджеттан тыш фондлары белән идарә итү органнары һәм аларның территориаль органнары, ведомстволарындагы казна һәм бюджет учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләрен (алга таба – нормалаштыру кагыйдәләре) раслый торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары түбәндәгеләрне билгеләргә тиеш:

норматив чыгымнарны исәпләү тәртибен, шул исәптән исәпләү формулаларын;

нормалаштыру кагыйдәләрендә билгеләнгән норматив чыгымнарны исәпләү тәртибен куллану буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт бюджеттан тыш фондлары белән идарә итү органнары һәм аларның территориаль органнары, ведомстволарындагы казна һәм

бюджет учреждениеләре бурычын.

10. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт бюджеттан тыш фондлары белән идарә итү органнары һәм аларның территориаль органнары, ведомстволарындагы казна һәм бюджет учреждениеләре һәм дәүләт унитар предприятиеләренә беркетелгән дәүләт идарәсе функцияләре кысаларында вәкаләтләрне тормышка ашыруга норматив чыгымнарны исәпләгәндә кулланыла торган заказчылар сатып ала торган товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләренә таләпләрне, товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр саны исемлеген һәм нормативларын, аларның куллану сыйфатларын һәм бүтән сыйфатламаларын билгеләү кагыйдәләрен раслый торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары түбәндәгеләрне билгеләргә тиеш:

товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр саны исемлеген һәм нормативларын, аларның куллану сыйфатларын һәм бүтән сыйфатламаларын, шулай ук мондый сыйфатлар һәм сыйфатламаларның әһәмиятен;

ведомство исемлеген формалаштыру һәм алып бару тәртибен.

F:\KARAR\2017\186.docx